# БЕЛДЕРҮ

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасы һәм 39.18 статьясы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы түбәндәге характеристикалы җир кишәрлеген 20 елга арендага бирү турында хәбәр итә:

Кадастр номеры 16:23:140502:39, мәйданы 1453 кв.м, җир категориясе: «торак пунктлар җирләре», рөхсәт ителгән файдалану төре: « шәхси хуҗалык алып бару өчен » (Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматлар нигезендә), кишәрлекнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Янил авыл җирлеге, Вахит авылы, Урман урамы, 8 нче җир кишәрлеге.

Югарыда күрсәтелгән җир кишәрлеген арендага алырга кызыксынучы гражданнар аукционда катнашу нияте турында әлеге хәбәр басылып чыкканнан соң 30 көн эчендә язма рәвештә гариза (алга таба – гаризалар) бирергә хокуклы. Гаризаны гариза бирүче (ышанычлы зат) эш көннәрендә (дүшәмбе – җомга, эшләми торган бәйрәм көннәреннән, эшләми торган көннәр дип игълан ителгән көннәрдән, ял көннәре күчерелгән көннәрдән тыш) 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән сәгать 13.00 гә кадәр – төшке аш өчен тәнәфес белән) Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 нче йорт 101 кабинетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшыра ала.

Гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы – 2023 елның 20 ноябре, 15 сәгать 00 минут.